ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.08.2020 г. Заинск № 338

**"Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланың акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланың акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.урнаштырырга.

3.Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Юрист
И.П.Фәттахова
7 12 31

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең
07.08. 2020 ел
338 номерлы карарына
кушымта

**Законлы вәкилгә балигъ булмаган баланың акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Зәй муниципаль районы территориясендә яшәүче балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба - дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәт күрсәтүне алучылар: балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының башкарма комитеты (алга таба - опека һәм попечительлек бүлеге) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органының урнашкан урыны:

423520. Зәй шәһәре, Крупская ур., 6 йорт, 90 каб.

Опека һәм попечительлек бүлегенең гаризаларны кабул итү графигы:

сишәмбе 8.00 - 17.00,

пәнҗешәмбе 8.00 - 12.00,

шимбә, якшәмбе: ял көннәре

Ял итү һәм туклану өчен ял вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Җәмәгать транспортында “Җиңү бульвары” тукталышына кадәр барырга.

Керү - шәхесне ачыклаучы документ буенча.

Опека һәм попечительлек органының урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

1.3.2. Белешмәләр өчен телефон: 7 12 31

1.3.3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы (алга таба «Интернет» челтәре): http:/ www.zainsk.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www zainsk.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Башкарма комитетның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, шулай ук электрон почтасы турында мәгълүмат Башкарма комитетның опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www. zainsk.tatar.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 1994 елның 30 ноябрендәге 51 – ФЗ номерлы законның 1 өлеше (алга таба – РФ ГК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба-РФ ГК) («РФ законнары җыентыгы", 01.01.1996, №1, 16 ст.);

Россия Федерациясенең 2002 елның 14 ноябрендәге 138-ФЗ номерлы гражданлык-процессуаль кодексы (алга таба - РФ ГПК) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002 ел, 18 ноябрь; N 46 ст. 4532);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе

законнары җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба-Татарстан Республикасы Гаилә кодексы) (Татарстан Республикасы, 16.06. 2009, №8);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы 2.03. 2004, № 43-44);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (Татарстан Республикасы, 25.03.2008, №60-61);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК 880 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, №46, 2144 ст. 20.12.2011);

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2016 елның 17 мартындагы 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба - БК турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2006 елның 08 июнендәге 570 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Башкарма комитеты опека һәм попечительлек органы турында нигезләмә (алга таба – опека бүлеге турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 24 мартындагы 83 номерлы карары белән расланган Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба - кагыйдәләр).

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ гамәлләр срокларын һәм эзлеклелеген, аның структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хакимиятенең башкарма органының физик яисә юридик затлар (алга таба - дәүләт хезмәтләрен алучылар), дәүләт хакимиятенең һәм җирле үзидарәнең башка органнары, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәткәндә оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген билгели торган норматив хокукый акт;

- дәүләт хезмәте - федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге, ул мөрәҗәгать итүчеләр соравы буенча Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибенең (алга таба - шикаять) бозылуына карата шикаять - мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең бозылган хокукларын яисә законлы мәнфәгатьләрен торгызу турында дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затына, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә, дәүләт хезмәткәренә яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга, аларның хезмәткәрләренә таләбе;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк) - 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле, шул исәптән электрон рәвештә, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт яисә муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы - дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле гарызнамә яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән гарызнамә белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган принцип, ә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән үзара хезмәттәшлек норматив хокукый актлар һәм үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә гариза бирүче катнашыннан башка күп функцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыны - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы)

- техник хата - дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) шулар нигезендә кертелә торган документлардагы белешмәләрнең туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла. Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге регламентка 1нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләпләре исеме | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме | Балигъ булмаганның акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү | ст. 28 ГК РФ<br>ст. 37 ГК РФ<br>ст. 60 СК РФ |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге | ст. 5 Закона РТ №8-ЗРТ |
| 2.3 Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау. | Балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә, тәрбиягә алган ата-анага, опекунга (попечительгә) банкка хат рәвешендә рөхсәт яки баш тарту турында хат | ст. 28 ГК РФ<br>ст. 37 ГК РФ<br>ст. 60 СК РФ |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | Опека һәм попечительлек органының алдан рөхсәте, яки мондый рөхсәтне бирүдән баш тарту опекунга яки попечительгә мондый рөхсәт бирү турында гариза биргән көннән алып унбиш көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә бирелергә тиеш.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | ст. 21 ч. 3 № 48-ФЗ |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелергә | 1. Акчалата кертемне алуга рөхсәт сорап, ата-аналарның берсенең яисә аларны алмаштыручы затларның гаризасы;<br>2. Гариза бирүченең паспорты күчермәсе;<br>3. Балигъ булмаган баланың туу турында таныклык күчермәсе (паспорт); | |

| | | |
|---|---|---|
| тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә бәйле булган хезмәтләр исемлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, | 4. Опека билгеләү турында муниципаль хокукый акт күчермәсе (опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар өчен). | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Теркәлү турында белешмә (форма №9) | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бирелгән документларның 2.5 пунктта күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелә торган документлар тиешенчә рәсмиләштерелмәгән;<br>3. Гражданның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Хезмәтне туктатып тору яисә күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәтне күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:<br>1. Акчаларның балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә тотылмау фактын билгеләү;<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү хокукы билгеләнә торган документлар тиешенчә рәсмиләштерелмәгән, тулы түгел һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматлар бар;<br>3. Балигъ булмаган баланың мөлкәткә хокуклары кысылу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп. | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты. | Чират булганда муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирү - 15 минуттан артык түгел. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте | Гариза кергән көндә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә. | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамәләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре булган мәгълүмати стендларга һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, шул исәптән күрсәтелгән объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә алар файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә таләпләр. | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын, санитар-эпидемиологик иминлек таләпләренә җавап бирә торган күпфункцияле үзәк биналарында гамәлгә ашырыла. шулай ук алар янгын сүндерү һәм гадәттән тыш хәл килеп чыгуы турында хәбәр итү чаралары, һаваны сафландыру системасы, мөрәҗәгать итүчеләрнең иминлеген һәм уңайлы эшен тәэмин итә торган башка чаралар, шул исәптән документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары, техник чаралар белән җиһазланган булырга тиеш.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчену).<br>Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып | |
| 2.15. 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>-бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>-белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>-мәгълүмат стендларында, “интернет” | |

| | | |
|---|---|---|
| барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүченең теләге буенча (экстриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында Федераль законның 15 статьясында каралган гарызнамә аша (комплексылы запрос ) | челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында (http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>инвалидларга бүтәннәр белән бер дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>-мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итү һәм бирүдә чиратлар;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата нәзакәтсезлегенә, илтифатсызлыгына шикаять.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә үзара элемтәсе фаразлана. Үзара элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән тәгаенләнә.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә консультацияне, документларны алу-бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮдә | |

| | | |
|---|---|---|
| | алынырга мөмкин<br>. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр. | Консультация интернет-кабул итү аша бирелә<br>Электрон рәвештә гариза һәм документлар, рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләре күрсәтелә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. | Федеральный закон № 63-ФЗ |

## 3. Состав, последовательность и сроки выполнения административных процедур (действий), требования к порядку их выполнения, в том числе особенности выполнения административных процедур (действий) в электронной форме

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Балигъ булмаганның акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны, документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5. пункты нигезендә);

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә, рөхсәтне яки нигезләр булганда, баш тарту турында хатны әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) нигез булганда мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта аша (адресы: zaiopeka@mail.ru) һәм (яисә) хат белән консультацияләр алу тәртибе турында опека һәм попечительлек органына (алга таба - бүлек) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен тапшырыла торган документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча ярдәм күрсәтә.

Бүлек белгече дәүләт хезмәтен алу предметына мөрәҗәгать итүчене консультацияли, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, искәрмәләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене, документларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны опека һәм попечительлек органына тапшыра.

3.3.2. Кабул итүне алып баручы опека һәм попечительлек бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

документларның булуын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килештерелмәгән башка төзәтүләр булмау).

Әлеге регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм бирелгән керү номеры белән документларны кабул итү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге регламентның 3.3.3. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуын шәхсән үзе хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, расписка яисә гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Хезмәттән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек бүлеге белгече баш тарту турында хат әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә хатка кул куйган датадан 2 көн эчендә бу турыда җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла һәм әлеге регламентның 3.7 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен оештыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада запрос җибәрә:

- бала яшәгән урыннан теркәлү турында белешмә бирү турында (9 нчы форма).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат сорап җибәрелгән запрос.

3.4.2. Опека һәм попечительлек бүлеге запрослары буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла:

- запросны эшкәртү һәм соралган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара электрон бәйләнеш аша формалаштыру, йә, соратып алына торган мәгълүматлар булмаганда, соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамәне җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары запрослары кергәннән соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: запроска җавап яисә шушы регламентның 3.4 п. күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Балигъ булмаганның акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү турында яисә баш тарту турында хат әзерләү

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тәкъдим ителгән документлар нигезендә балигъ булмаганның акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт проектын яки законлы вәкилгә балигъ булмаганның акчалата кертемен алудан баш тарту турында дәлилләнгән хат әзерли һәм аны килештерүгә опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: законлы вәкилгә балигъ булмаганның акчалата кертемен алуга рөхсәт бирү яки 3.7 пункт нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган рөхсәтне алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра (җибәрә). Тискәре нәтиҗә булган очракта, заказлы хат белән почта аша 3.7 п. нигезендә хәбәрнамә бирә (җибәрә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, 3.5.1 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү:

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Әзерләнгән хат проектын кул кую өчен опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалауга җибәрелгән баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе баш тарту турында дәлилләнгән хат проектына кул куя һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.1. пунктча белән каралган процедура тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелганнан соң 2 көн эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документларны кире кайтара һәм карарга шикаять бирү тәртибен аңлата.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пункча белән каралган процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.8. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша дәүләт хезмәте күрсәтү

3.8.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгеннән документлар килгәндә, процедуралар әлеге регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә җибәрелә.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетка тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (7 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хата булган документны;

юридик көчкә ия, техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырыла.

3.9.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече документларны хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында карый, шушы регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып, кул куйдырып, төзәтелгән документны бирә, яисә Башкарма комитетка техник хата булган документның оригиналын тапшырганда, төзәтелгән документны алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта аша) мөрәҗәгать итүчегә хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, опека һәм попечительлек бүлеге, КФҮ вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору формалары түбәндәгеләр:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә алып барыла торган эшләр башкаруны тикшерү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында КФҮ, опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен оештыруга җаваплы белгеч, эшләр башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Срокларны, административ процедураларны бозу очраклары һәм сәбәпләре турында белгечләр кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтә торган

орган җитәкчесенә хәбәр итә, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге КФҮ структур бүлекчәләре, опека һәм попечительлек органы һәм вазыйфаи регламентлар турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы хезмәткәр мөрәҗәгать итүченең гаризасын үз вакытында карамаган өчен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән нигезсез баш тарткан өчен җавап бирә.

Җаваплы башкаручылар дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә торган (башкарыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаулар) өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү йөкләнгән оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципальхезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлеше нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү йөкләнгән оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерергә хокуклы.

5.1. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, гаризаны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә карата шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы

1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү йөкләнгәнсә мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яисә мәгълүматны бирүне яисә гамәлләрне башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Зәй муниципаль районы хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Зәй муниципаль районының хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә йөкләнгәндә мөмкин;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Зәй муниципаль районы хокукый актлары белән каралмаган түләүне таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлеше нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү йөкләнгән оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документларда җибәрелгән опечатка һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә йөкләнгәндә мөмкин;

8) дәүләт хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү вакытын яисә тәртибен бозу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Зәй муниципаль районының хокукый актларында каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә йөкләнгәндә мөмкин;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда, аларның булмавы яисә дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, таләп итү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә йөкләнгәндә мөмкин.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә йә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына) һәм шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә йә ул булмаган очракта муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәкнең җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар. КФҮ, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, КФҮ рәсми сайтын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук

гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, «Интернет» мәгълүматтелекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар.

5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне эчендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешманың мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуы яисә җибәрелгән опечаткалар һәм хаталарны төзәтүдә яисә билгеләнгән срокны бозу очрагында  теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның вазыйфаи затының, аның җитәкчесенең һәм (яки) 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең исемнәре;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда, аның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче

органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән мөрәҗәгать итүченең риза булмаган дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәлилләрне раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә муниципаль хезмәт алучы тарафыннан имза салына.

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет җитәкчесе (муниципаль район башлыгы) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, ул кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, җибәрелгән хаталарны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтү рәвешендә, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә булырга мөмкин;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгәнчә, карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясы 8 өлешендә күрсәтелгәнчә, гариза язучыга җибәрелә торган җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә киткән җитешсезлекләрне тиз арада төзәтү максатыннан, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясын 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенеп, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтне алу максатларында алга таба башкарырга кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять, әлеге бүлекнең 5.9 пунктында күрсәтелгәнчә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерелми дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәләр буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау буенча 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясы 1 өлеше нигезендә вәкаләтләр бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат җиткерү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү, шул исәптән комплексլы ведомствоара соратулар буенча;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификацияле цифрлы электрон имзасының гамәлдә булуын тикшерү;

5) Башкарма комитетка документлар белән бергә гаризаны җибәрү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

6.2.Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮгә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru/) ирекле керү юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша яисә электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гаризаны, шушы регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны КФҮгә, КФҮнең читтәге эш урынына тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6.3.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ белгече КФҮ эше регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

6.4.1. КФҮ белгече КФҮнең эш регламенты нигезендә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификацияле цифрлы электрон имзасының гамәлдә булуын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга, шул исәптән комплекслы ведомствоара запрос буенча, ведомствоара запросларны формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.

6.4.2. МФЦ белгече запросларга җавапларны алганнан соң документлар пакетын формалаштыра һәм аны Башкарма комитетка КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар

6.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү

6.5.1. КФҮ белгече дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Башкарма комитеттан алгач, аны билгеләнгән тәртиптә терки. Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитеттан документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

6.5.2. КФҮ белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, гариза бирүченең килү көнендә КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе.

Балигъ булмаганнарның акчалата
кертемен алуга рөхсәт бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1нче кушымта

___________________________________

____________________________________
кемнән
____________________________________,
(Ф.И.А. тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
____________________________________
_____________________________________
(тулы адрес)
телефон:___________________________
паспорт:___________________________
(серия, номер, кем тарфыннан бирелгән)

Гариза.

Минем улымның (кызымның), опекунымның акчалата кертемен алу өчен ______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган баланың Ф.И.А. тулысынча)
___________________ елда туган, с принадлежащего ему счета в ____________________________________ банкындагы аның счетыннан, кирәк булу сәбәпле ______________________________________________________________________________
_, (баланың акчасын алу сәбәбен аңлатырга)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________ рөхсәт бирүегезне сорыйм.

___________________кадәр опека органына минем балам (опекага алынган) мәнфәгатьләрендә акча сарыф итүне раслый торган документларны тапшырырга йөкләмә алам.

«___» ________________ 2020 ел. _________________
(имза)

Балигъ булмаганнарның акчалата
кертемен алуга рөхсәт бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2нче кушымта

___________________________________
_______

___________________________________
_______
кемнән
___________________________________
(Ф.И.А. тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
___________________________________
___________________________________
(тулы адрес)
телефон:

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин, ____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
түбәндәге адрес буенча яшәүче_____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон адресын күрсәтеп)
_____________________________________________________________________________________
(документның сериясе, номеры, бирү вакыты,
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
документны биргән органның исеме)
Улым (кызым)_______________________________________________ ның акчалата өлешен алуга бирелгән рөхсәттә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне сорыйм.
____________________________.
карарның датасы, номеры
Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза
_____________________________________________________________________________
(язмача, телефон буенча, смс-хәбәр, электрон почта аша)

«___»_____________20__ел. _______________ ___________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Балигъ булмаганнарның акчалата
кертемен алуга рөхсәт бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3нче кушымта

## Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | (8-85558)7 12 31 | zaiopeka@mail.ru |
| Бүлек белгече | (8-85558)7 12 31 | zaiopeka@mail.ru |

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-85558)3 41 31 | zainsk@tatar.ru |

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ЗАИНСКАЯ**
**ГОРОДСКАЯ ПРОКУРАТУРА**
Чапаева ул., 3, Заинск, 423520,
(8-85558) 7 27 59, e-mail: zainsk.prok@tatar.ru

29.05.2020 № 02-01-14/2020
На № 2271/ИК от 20.05.2020

Руководителю Исполнительного комитета Заинского муниципального района Республики Татарстан

Хафизову И.Ф.

**ЗАКЛЮЧЕНИЕ**
на проект муниципального нормативного правового акта

Направленный в соответствии с Федеральным законом от 17.07.2009 «Об антикоррупционной экспертизе нормативных правовых актов и проектов нормативных правовых актов» проект постановления Исполнительного комитета Заинского муниципального района Республики Татарстан «Об утверждении административного регламента предоставления государственной услуги по выдаче разрешения законному представителю на получение денежного вклада несовершеннолетнего» прокуратурой рассмотрен.

По результатам антикоррупционной экспертизы установлено, что решение соответствует Федеральному закону от 06.10.2003 № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления», Семейному кодексу РФ.

Внутренние противоречия правовых норм в муниципальном нормативном правовом акте отсутствуют. Содержащиеся в нем нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены.

Коррупциогенных факторов в положениях муниципального нормативного правого акта не содержится.

Городской прокурор
старший советник юстиции Р.Р. Каримов

И.П. Якупова, (85558) 7-06-94

Заинская городская прокуратура
№ Исорг-20920046-196-20/496-20920046